**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«__06___» ___09___ 2024 ел.** **№ __159__**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 25 сентябрендәге 239 номерлы «Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары булып торучы һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре Азнакай муниципаль районы бюджет системасы бюджетларының төп администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен башкару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 25 сентябрендәге 239 номерлы «Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары булып торучы һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре Азнакай муниципаль районы бюджет системасы бюджетларының төп администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен башкару Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның «б» подпунктының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, түләнергә тиешле сумманы, физик һәм юридик затларның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өчен акчалата чараларын түләү өчен кирәкле мәгълүматны, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен формалаштыру чыганаклары булган башка түләүләрне «Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында»гы 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә бирү;»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле җиденче - сигезенче абзацларны өстәргә:

«бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү;

бюджетка түләүләр буенча дебитор бурычларын, өстәмә түләүләр һәм штрафлар буенча Россия Федерациясе Финанс Министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру регламентын билгеләү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм финанс буенча урынбасары О.Н. Газизовага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов